КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 2 август г.Казань № 751

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Бюджет өлкәсенең кайбер оешмалары хезмәткәрләре хезмәте өчен түләүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф сеткасы кагылмый торган бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәте өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 30 март, 195 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 20 июнь, 497 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1287 нче, 2021 ел, 07 декабрь, 1189 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 5 пунктның 6 пунктчасындагы өченче абзацында «бер сәгать тариф ставкасының 7 проценты» сүзләрен «хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин